Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № XLV-4**

Балык Бистәсе штп. 2019 елның 24 сентябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2013 елның 27 сентябрендәге XXVIII-2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында бюджет процессы турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актны законнар белән тәңгәллеккә китерү максатларында, 2019 елның 2 августындагы "Бюджетара мөнәсәбәтләрне камилләштерү максатларында Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында" 307-ФЗ номерлы Федераль закон, 2019 елның 26 июлендәге "Россия Федерациясе Бюджет кодексына дәүләт (муниципаль) финанс контролен, эчке финанс контролен һәм эчке финанс аудитын камилләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү турында" 199-ФЗ номерлы Федераль закон, 2019 елның 2 августындагы "Дәүләт (муниципаль) үзләштерүләре, дәүләт (муниципаль) бурыч һәм Россия Федерациясе дәүләт финанс активлары белән идарә итү өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салуны камилләштерү максатларында Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм "Дәүләт һәм муниципаль кыйммәтле кәгазьләренең эмиссиясе һәм әйләнеш үзенчәлекләре турында" Федераль законның көчен югалтуын тану хакында" 278-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2013 елның 27 сентябрендәге XXVIII-2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында бюджет процессы турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) 3 мадденең 5 пункты 2 абзацын "җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен төзелгән килешүләр нигезендә гамәлгә ашыруга" сүзләре белән тулыландырырга;

1.2) 7 маддәне түбәндәге эчтәлектәге 14 пункт белән тулыландырырга:

"федераль законнарга һәм Татарстан Республикасы законнарына ярашлы рәвештә муниципаль район бюджетына алынырга тиешле аерым салым булмаган керемнәрдән шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына керемнәрне чигерү (аерып кую) нормативларын билгеләү;";

1.3) 20 маддәнең 4 пунктында “һәм 46” сүзләрен “,46, 58, 63 һәм 63.1” сүзләренә алмаштырырга;

1.4) 26 маддәнең 1 пункты 4 абзацын көчен югаткан дип танырга.

1.5) 1 бүлекнең 29 маддәсе 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3.Районның финанс-бюджет палатасы бирелгән гарантияләрнең, алар буенча үзидарәлек бурычының арту, принципаллар (төп бурычлылар) яисә өченче затлар тарафыннан принципалларның гарантияләр белән тәэмин ителгән йөкләмәләрен тулы күләмдә яки кайсыдыр өлешен үтәү нәтиҗәсендә үзидарәлек бурычының кыскару, принципалларның гарантияләр белән тәэмин ителгән йөкләмәләрен тулы күләмдә яки кайсыдыр өлешен башка нигезләр буенча туктату, бирелгән гарантияләр буенча түләүләр гарантын гамәлгә ашыру, шулай ук үзидарәлек гарантияләре белән билгеләнгән бүтән очракларда исәбен алып бара.”;

1.6) 40 маддәдә:

а) 5 пунктның беренче абзацын көчен югалткан дип танырга;

б) түбәндәге эчтәлектәге яңа икенче һәм өченче абзацлар белән тулыландырырга:

“Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы финанс-бюджет палатасы бюджет һәм акча йөкләмәләрен (бурычларын) исәпкә куйганда, акча йөкләмәләрен (бурычларын) түләүне раслаганда Россия Федерациясе Бюджет кодексының 219 маддәсенең 1 пунктында күздә тотылган, Россия Финанслар министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртип нигезендә түбәндәгегә контрольне гамәлгә ашыра:

бюджет йөкләмәләренең бюджет йөкләмәләренең тиңдәшле лимитларыннан яки бюджет средстволарын алучыларга җиткерелгән бюджет ассигнованияләреннән артып китмәвенә, шулай ук бюджет йөкләмәсе турындагы мәгълүматның бюджет чыгымнары классификациясе кодына туры килүенә;”;

в) түбәндәге эчтәлектәге дүртенче – сигезенче абзацлар белән тулыландырырга:

“акча йөкләмәсе (бурычы) турындагы мәгълүматның исәпкә куелган тиңдәшле бюджет йөкләмәсе турындагы мәгълүматка туры килүе;

акча йөкләмәсен (бурычын) түләү өчен түләү документында күрсәтелгән мәгълүматның акча йөкләмәсе (бурычы) турындагы мәгълүматка туры килүе;

акча йөкләмәсе (бурычы) барлыкка килүне раслаучы документларның булуы.

Россия Финанслар министрлыгы тарафыннан билгеләнгән һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексының 219 маддәсенең 1 пунктында күздә тотылган тәртиптә әлеге пунктта күрсәтелгән мәгълүматка өстәмә буларак контрольдә булырга тиешле башка мәгълүмат тәгаенләнергә мөмкин.

Бюджет йөкләмәсе (бурычы) үзидарәлек контракты нигезендә барлыкка килгән очракта үзидарәлек контракты турында мәгълүматларның дәүләт һәм үзидарәлек ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнарында күздә тотылган контрактлар реестрында туры килүенә, үзидарәлек контракты нигезендә барлыкка килгән бюджет йөкләмәсен исәпкә алу турындагы мәгълүматларның үзидарәлек контракты шартларына туры килүенә өстәмә контроль гамәлгә ашырыла.”;

г) икенче, өченче һәм дүртенче абзацларны тиңдәшле рәвештә тугызынчы, унынчы һәм унберенче абзацлар итеп санарга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көннән үз көченә керә, әлеге карарның 3 пункты өчен көченә керүнең бүтән срогы тәгаенләнгән нигезләмәдән гайре.

3. 1 бүлекнең 29 маддәсе 3 пунктына кертелгән үзгәрешләр 2020 елның 1 гыйнварыннан көченә керә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының бюджет,финанслар, икътисад, җирле салымнар һәм эшкуарлык буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы И.Р. Таҗетдинов